РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ СТАРОИКШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Старая Икшурма, ул. Ленина, д.17
тел. (84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы, Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел. (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
07.09.2020

КАРАР
№26

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 2019 нчы елның 25 нче октябрендә кабул ителгән 35 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 20.07.2020 ел, № 236-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советы тарафыннан 2019 нчы елның 25 нче октябрендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 35 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.8 гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

- әлеге торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертүгә китерә торган әлеге торак пункт составына кергән җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча торак пунктта;

- муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә әлеге җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча;

- әгәр җирлекнең сайлау хокукына ия халкы саны 100 дән артык булса, җирлекнең вәкиллекле органы тезү, аның саны һәм вәкаләтләре вакыты турындагы мәсьәлә буенча;

- муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча;

- җирлек составына керүче торак пунктта, муниципаль район чикләрендә, әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

- авыл торак пунктында авыл җирлеге старостасы кандидатурасын тәкъдим итү, шулай ук авыл торак пункты старостасының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

- авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелергә мөмкин.

- муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча;

- җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта, яңа төзелгән җирлек төзү турында халык инициативасын тәкъдим итү максатларында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр аның сайлау хокукына ия халкы саны 300 кешедән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча;

- авыл халкының түбән тыгызлыгы булган территориядә яки үтеп керү авыр булган җирлектә, әгәр авыл җирлегендә халык саны 100 кешедән дә артмаган булса, җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча”

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/ikshurma адресы буенча, җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз естемә алам.

Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы урынбасары: И.Ә.Гәрәфиев